КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 17 июнь г.Казань № 580

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга, акушеркаларга, фельдшерлык һәм фельдшерлык-акушерлык пунктларының шәфкать туташларына) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен һәм Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга, акушеркаларга, фельдшерлык һәм фельдшерлык-акушерлык пунктларының шәфкать туташларына) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 22 апрель, 319 нчы карары белән расланган Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга, акушеркаларга, фельдшерлык һәм фельдшерлык-акушерлык пунктларының шәфкать туташларына) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга, акушеркаларга, фельдшерлык һәм фельдшерлык-акушерлык пунктларының шәфкать туташларына) бер тапкыр бирелә

торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен һәм Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга, акушеркаларга, фельдшерлык һәм фельдшерлык-акушерлык пунктларының шәфкать туташларына) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 22 апрель, 319 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 25 февраль, 97 нче, 2021 ел, 12 май, 328 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга, акушеркаларга, фельдшерлык һәм фельдшерлык-акушерлык пунктларының шәфкать туташларына) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртибенә, 8 пунктка «в» пунктчасын өстәп, үзгәреш кертергә:

«в) югары белем бирү мәгариф оешмаларында яисә һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы һөнәри белем бирү оешмаларында (шул исәптән максатчан уку турындагы шартнамә нигезендә) белем алу тәмамланганнан соң медицина хезмәткәреү үзе яшәгән урында урнашкан медицина оешмасына үзе теләге белән эшкә урнашканда (авыл торак пунктында, йә эшчеләр бистәсендә, йә шәһәр тибындагы поселокта, йә 50 мең кешегә кадәр халкы булган шәһәрдә).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин